**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 11 «19» март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (18.08.2015 № 20, 02.11.2015 № 10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66, 21.06.2019 №25, 25.11.2019 № 48 карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлеге Уставы белән,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының «Физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 25 ноябрендәге 42 номерлы карарына (18.08.2015 № 20, 02.11.2015 № 10, 04.05.2018 № 21, 13.11.2018 № 59, 13.12.2018 № 66, 21.06.2019 №25, 25.11.2019 № 48 карарлар редакциясендә) 3.2 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган салым түләүчеләр үзләре сайлаган салым органына салым ташламаларын бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatastan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы бистә Советының бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов